**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

---

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

15.02.2021 108-п

Татарстан Республикасы территория-сендә урнашкан Морквaш елгасы, Мәме елгасы, Келәнче елгасы, Сумка елгасы, Болак ермагы су объектлары-ның Казан шәһәрендә су саклау зона-ларын һәм яр буе саклык полосаларын билгеләү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 10 гыйнварындагы 17 номерлы карары белән расланган Су объектларының су саклау зоналары чикләрен һәм яр буе саклык полосалары чикләрен билгеләү кагыйдәләре, Россия Федерациясе Су кодексы, «Күчемсез мөлкәтне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законның 32 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 325 номерлы карары нигезендә һәм «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан Морквaш елгасының, Мәме елгасының, Келәнчеы елгасының, Сумка елгасының һәм Казан шәһәре һәм Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендәге 35 сулыкның яр линияләре урнашкан урыннарны (су объектларының чикләрен), су саклау зоналары чикләрен һәм яр буе саклык полосалары чикләрен билгеләү» 2020 елның 13 апрелендәге № 20 МЭ-1ф дәүләт контракты кысаларында башкарылган эш нәтиҗәләре буенча, су объектларының су саклау зоналары чикләре һәм яр буе саклык полосалары чикләре турындагы белешмәләрне дәүләт су реестрына һәм Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертү максатында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларының су саклау зоналары һәм яр буе саклык полосалары киңлеген Россия Федерациясе Су кодексының 65 статьясы нигезендә әлеге чикләрдә хуҗалык һәм башка төр эшчәнлекне гамәлгә ашыруның махсус режимын исәпкә алып билгеләргә:

1.1. Морквaш елгасы:
су саклау зонасының киңлеге – 50 м;
яр буе саклык полосасының киңлеге: ярның авышлыгы 3 градустан күбрәк

булганда – 50 м.

1.2. Мәме елгасы:

су саклау зонасының киңлеге – 100 м;

яр буе саклык полосасының киңлеге: ярның авышлыгы 3 градустан күбрәк булганда – 50 м.

1.3. Келәнче елгасы:

су саклау зонасының киңлеге – 100 м;

яр буе саклык полосасының киңлеге: ярның авышлыгы 3 градустан күбрәк булганда – 50 м.

1.4. Сумка елгасы:

су саклау зонасының киңлеге – 100 м;

яр буе саклык полосасының киңлеге: ярның авышлыгы 3 градустан күбрәк булганда – 50 м.

1.5. Болак ермагы:

су саклау зонасының киңлеге – 50 м.

2. Су объектларын саклау бүлегенә (В.А. Долгов) материалларны билгеләнгән тәртиптә дәүләт су реестрына кертү өчен Су ресурслары федераль агентлыгына җибәрергә.

3. Экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү өлкәсендәге проектларны пропагандалау бүлегенә (Л.Н.Мөлекова) әлеге боерыкны татар теленә тәрҗемә итәргә.

4. Хокукый тәэминат бүлегенә (А.И.Ткачук) әлеге боерыкны теркәү өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

5. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары А.М.Шиһаповка йөкләргә.

Министр А.В. Шадриков